Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге ТатЦИК ис.торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

27 октябрь, 2022 года № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге ТатЦИК ис.торак пунктындагы гражданнар җыенының 2022 елның 27 октябрендәге йомгаклау беркетмәсе нигезендә карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1. статьясындагы 2 өлеше, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлешендә) гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәнең 5 өлешендәге 5 пункты нигезендә түбәндәге сорау буенча: «Сез, 2023 елда ТатЦИК исемендәге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарын, 80 яшькә җиткән гражданнарны, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау

**гражданнар җыены үтмәгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Шәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Шәле авыл җирлеге башлыгы И.Р. Әхмәтҗанов